**Алар даны мәңгелек**

*( Бөек Җиңүнең 78 еллыгына багышланган сценарий)*

**Максат.** Укучыларны Бөек Ватан сугышы чоры белән таныштыру; авылдашларыбызның Җиңүне якынайтуга керткән батырлыклары һәм тырыш хезмәтләре белән таныштыру; сугыш афәтенең һәр кеше, һәр гаилә өчен фаҗига булуын төшендерү; сугыш һәм тыл ветераннарына олы хөрмәт хисе тәрбияләү; сугыш елларының бар авырлыгын үз җилкәләрендә татыган балалар язмышының ачылыгын аңлату; тыныч тормышның кадерен белеп, үткәннәргә ихтирам белән караучы шәхес тәрбияләү.

**Җиһазлау**. Бөек Ватан сугышы чорына багышланган иҗади эшләр күргәзмәсе, “Сезнең тормыш – үзе батырлык” стенды, стена газеталары.

**Техник чаралар**: интерактив такта, сугыш чоры балаларына багышланган компьютер презентациясе, ноутбук.

Зал чәчәкләр һәм тасмалар белән бизәлгән. Талгын гына музыка астында ике алып баручы чыга.

1 нче алып баручы.

Язлар үтеп, ямьле җәйләр килде
Туган ягым күмелде чәчәккә.
41 нең җәен халык каршылый
Зур өметләр баглап киләчәккә.

Ак болытлар өерен тирбәтеп
Җылы җилләр тагын истеләр.
Кояш нуры белән бизәлешкән
Күбәләкләр очып киттеләр.

2 нче алып баручы.

Күкрәк киереп, гөлләр таҗын җилпи
Күрегез, күр безне, дигәндәй.
Тоелалар алар сәлам юллап,
Бер-берсенә башын игәндәй.

Шул иртәдә печән чабу өчен
Авыл халкы чыкты болынга
Күмәкләшеп, өмә ясап эшли-
Шундый гадәт борын-борыннан.

1 нче алып баручы.

Сызганулы кулда чалгы,
Эх, ул яшел печән исләре...
Эшкә дәрт һәм кулга дәрт бирә
Туган якны ярату хисләре.

**Сафиуллина Лилия “Чишмә башы” җыр**

*Солдатларны **сугышка озату күренеше**. Биюче егетләрне ана һәм кызлар озатып кала*

**Ана.**

**Сәхнә алдына ике алып баручы чыга.**

**1.** Сугыш... Меңләгән шәһәрләр җимерелгән, җир йөзеннән гөрләп торган авыллар юкка чыккан, шау чәчәккә күмелгән бакчалар янып көлгә әйләнгән. Коточкыч сугышка безнең авыл җирлегеннән ___________якташыбыз киткән һәм аларның бары тик ______сына гына туган якка әйләнеп кайтырга насыйп булган.

**2.** Әйе... Барлык ир-егетләр сугышка китәләр, авылда картлар, хатын-кызлар, балалар калалар. Ә тормышны алып барырга кирәк иде – игенен дә игәргә, балаларны да ач-ялангач итмәскә, сугыш кырына икмәген, коралын да озатырга, бик зур салымын да түләргә кирәк була.

***Зал уртасында авыл өе күренеше. Хатын-кызлар оекбаш бәйләп утыра. Фатыйма бер тәрәзәдән- бер тәрәзәгә карап йөренә.***

***Катнашалар:***
***Мәргубә: Ана***
***Фатыйма: Мәргубәнең килене***
***Хәдичә: Күрше хатыны***
***Хат ташучы кыз:***

**Хәдичә:** Мәргүбә малаеңнан бер дә хәбәр алганыгыз юкмыни соң?
**Мәргүбә**: Юлдан гына бер хат язган иде, шуннан соң бер хәбәр дә булмады. Әнә киленебез дә җанын кая куярга белми, бик кайгыра.
**Хәдичә:** Сугыш бит инде ул Мәргүбәкәем, шулай да бер хәбәр булмый калмас әле.
**Мәргүбә:** Белмим инде... Әнә, гел күңелсез хәбәрләр генә ишетелә. Яраланган килеш дошман кулында калган солдатлар да бик күп дип сөйлиләр.
**Фатыйма**: Ул кадәр үк өметсезләнмик әле, әнкәй.
**Мәргүбә**: Үлгәндер инде үлгәндер. Якыннарының күңеленә авыр булмасын дип юри әйтми торганнардыр әле. Менә бу оекбашны да барлык җан җылымны салып улыма дип бәйләдем.
**Хәдичә**: Әйе, без һәрберебез, авылдагы барлык ялгыз калган аналар,улларыбызга һәм фронттагы ирләребезгә оекбаш-бияләйләр бәйләдек. Шушы җан-җылыбызны биреп бәйләгән әйберләр аларга көч-куәт биреп торсын иде.
**Мәргүбә**: Амин шулай булсын.
**Хәдичә**: Ирләр сугышта булгач авыл тып-тын калды, кичләрен кызларның җырлаган тавышлары да ишетелми .
**Мәргүбә:** Җыр дигәннән безнең киленебез дә бик матур итеп җырлый белә бит. Әйдәле, Фатыйма кызым бер күңелләрне юат әле.

***Фатыйма "Шәмдәлләр" дигән җырны җырлап җибәрә . Хәдичә белән Мәрглап күз яшьләрен сөртәләр.***

**Хәдичә:** Киленең эшкә генә түгел, җырларга да оста икән. Рәхмәт кызым.

***Шул вакытта ишек шакыйлар.***

**Фатыйма**: Әнкәй, әнкәй хат ташучы кереп килә безгә, бәлки шатлыклы хәбәрләр алып киләдер.
**Тыштан ишетелә:** Фатыйма апа сезгә Илһам абыйдан хат бар, иң беренче сезгә килдем.
**Фатыйма:** Әй рәхмәт яугыры. Әнкәй, Илһамнан хат бар.
**Мәргүбә**: Укы кызым, тизрәк укы, ниләр язды микән?

**Фатыйма хат укый.**

"Исәнмесез, минем өчен якын , кадерле , газиз туган якларда яшәп ятучы әнием, сөекле Фатыймам. Сезгә сагынычлы кайнар сәламнәр җибәреп фронттан Илһам хат яза. Сәлам барча туганнарга, күршеләргә һәм мине сораганнарга.

Сөекле әнием, сәламәтлекләрең ничек? Фатыйманың эшләре ничек бара? Авылда нинди яңалыклар бар? Менә тагы ямьле язлар җитә. Сезнең белән күрешү көннәрен түземсезлек белән көтәм. Тиздән, бик тиздән дошманны җиңеп, туган якларга әйләнеп кайтырбыз."

***Магнитофон язмасында Илһамның тавышы:***

Хуш, акыллым, соңгы сәламемне
Юллыйм сиңа җилләр аркылы,
Барсын сиңа кайнар сәлам булып
Йөрәгемнең сүнмәс ялкыны.
Бик күңелем булыр җиңеп кайтып,
Бил кысышып җылы күрешү;
Өмет, җаным, болай шәп шәбен дә,
Ләкин... сугыш уен түгел шул!

Хуш, акыллым, әгәр кайта алмасам,
Яраланып юлда егылсам,
Йөрәгемдә саклап ялкынымны,
Акрын-акрын тәнем суынса,
Хуш, акыллым!
Соңгы минутта да
Мин уйлармын синең турында.

1. Ут әчесе тоеп кайгы кичкән,
Хаклык күңеле тирән яралы.
Нәфрәт уты бөркеп сулыш ала
Үч алу бит аның карары.
Дәхшәт куба, кырлар яна гүләп
Җир актарып туплар ярыла.
Яшь батырның барыр юлларына
Утлы төтен, ялкын сарыла.

2. Озак бара көрәш каты була
Дошман явы күпләп кырыла.
Ләкин батыр егет үзе бер иртәдә
Ятып кала сугыш кырында.

**Сәләхетдинова Эльвина җыр**

**1 нче алып баручы.** Илебезне кара кайгыга салган, бик күпләрне ятим иткән, яшь кызларны гаиләсез, хатыннарны тол калдырган иң канкойгыч, иң мәрхәмәтсез сугыш тәмамлануга тиздән 70 ел була. Арабызда бу сугышны үз җилкәләрендә татыган, аның бар авырлыкларын кичергән ветераннар юк диярлек инде.

**2 нче алып баручы.** Тылда, ачлык-ялангачлыкта фронттагы солдатларыбызга аз булса да җиңеллек китерик дип, бар авыр эшне үз җилкәләренә салган апаларыбыз да берәм-берәм арабыздан китеп баралар. Балачаклары бу каһәр суккан сугыш елларына туры килгән абый-апалар да инде бик өлкән яшьтә.

**1 алып баручы.** Авыл башына чыгып, хатыннар ирләрен, ваемсыз сабыйлар әтиләрен, яшь кызлар сөйгәннәрен фронтка озата. Берни аңламаган сабыйлар сугышның нинди куркыныч икәнлеген белмиләр шул әле.Тиздән, бик тиздән үзләренең ятим каласыларын да, балачаклары буразна арасында үтәселәрен дә аңламый алар. Сугыш рәхимсез. “Әткәй, китмә!”- диеп елаган балалар инәлүен дә ишетми ул сугыш.

**2 алып баручы**. Әйе, авылда карт –коры, хатын-кыз һәм балалар кала. Сабый чагын күрми, күпме михнәт , авыр хезмәт татый аның әле өлгереп тә җитмәгән иңнәре. Тормышны алып барырга кирәк: кырда игенен дә игәргә, ач-ялангач та булмаска, сугышка төрле җылы киемнәр дә әзерләргә , гомер буе бетмәс кебек тоелган налогын да илтеп түләргә. Әтиләре, абыйлары сугыш кырында батырларча көрәшкәндә, тылда әниләр, сабый балалар үзләрен аямыйча эшлиләр.

5 УКУЧЫ.
Чабатадан, тездән суга батып,
Язгы чәчү җитәр алдыннан,
Чыгып киткән икән симәнәгә
Хатын-кызлар безнең авылдан.
Сыерлары юлда ятып калган,
Җилкәләргә күчкән симәнә.
Бу турыда сөйләгәндә
Әбкәй һаман елап җибәрә.
Кырык-илле чакрым язгы суда-
Кайталмасаң, илең ач кала.

Хатыннарда тик бер генә хәсрәт-
Өйдә көтә аны ач бала.
6  УКУЧЫ.
Сез, өлкәннәр, беләм, сызланасыз
Көзге дымлы җилләр искәндә.
Ап-ак чәчләр, ап-ак нурлы йөзләр,
Ә яшегез җитмеш-сиксәндә.
Далаларда кала салдыгыз сез
Болгавыр һәм каһәр елларда.
Бишьеллыклар үрен яуладыгыз,
Урак, чүкеч тотып кулларга.
Яу кырында калган әткәй, абый,
Төшегезгә керә бүген дә.
Кайгы булып яткан сары яфрак
Зираттагы каен төбендә.
Ташкын күңел ярдан ашканда да,
Алиһәдәй була белдегез.
Үзегез дә, бәлки, сизмисездер,
Шундый инде менә изге сез.
"Оныкларым туен күрдем", – диеп
Төренсәң дә бер көн ефәккә,
Ачы юа, кукы кәлҗемәләр,
Тәме сеңгән хәтта йөрәккә.

Сез, өлкәннәр, беләм, сызланасыз,
Дымлы җилләр исә, көн ятим.
Шигъри юрган салыйм иңегезгә,
Нишлим инде тагын, нишләтим?

Сугыш беткәнгә дә 70 ел җитеп  килә, әмма аның дәһшәте – көл булган шәһәр авыллар өстендә, яу кырыннан кайтмый калган ир- егетләр , әти- бабалар каберлегендә. Аның сары сагышы әтисезләр йөзендә. Алар сугыш дигән ачы хәсрәтнең фаҗигасен туганнан ук тоеп, үз күзләре белән күреп, ачлык- ялангачлыкның ни икәнен татып үскән. Алар утлы елларда туган балалар. Шуңа күрә сабыр, нык  алар.

**Хабибуллин Рифнур җыр**

2 нче укучы
Әтиләре сугышып йөргән чакта,
Аларның яңа туган елы булган.
Капчык аскан егермеләп хатын
Басуларга кайтып егылган.
Тәпи йөрер- йөрмәс бала- чага
Буразнадан билчән утаган.
Илгә- икмәк, авыл үзе өчен
Көлчә салган алабутадан.
Бер бәләкәй көлтә ега алган
ул елларның хуҗасын.
Олылар кебек күтәргән бит шулар
Ил хәсрәтен, Ватан нужасын.

Җыр:_______________________________________________

9 нчы укучы

Сугыш чоры балалары
Офыкларга тулды кара төтен,
Төсен алды төтен далаларның.
Елга булып яше җиргә сеңде
Сугыш чорындагы балаларның.

Ил хәсрәте ирләр иңсәсендә,
Ат чыдамый торган авыр хезмәт.
Алтмыш тулмый җиргә иңә ирләр,
Илгә рәнҗеп, күрми кадер-хөрмәт.

Хәтер төпкеленнән ачы язмыш,
Сөрән сала авыл, калаларга.
Уйчан йөзләр, әле дә моңсу күзләр
Сугыш чорындагы балаларда.

.
.

1 а.б. Сынаган аларны бу дөнья ! Утларына салып яндырса да, бозларына салып туңдырса да, сындырмаган, шөкер бу дөнья! Туйдырмаган ләкин бу дөнья! Ә бит сындырырдай итеп сынаган…
2 а.б. Һәр өченче малай һәм кыз баланың әтисе , Ватанны фашизм коллыгыннан саклап, яу кырында ятып калган. Әлбәттә, бүген моны- ач калган һәм дә ятим балаларның ул чактагы хәлен – халәтен аңлавы кыен.
Шулай сугыштан соң да аталы балалар ата- ананың тигез канаты астында җылыга коенганда, алар сыңар канат астында «әти» дип әйтергә тилмергән. Япь- яшь килеш канатлары каерылган чибәр хатыннар солдат ирләренә булган мәхәббәтне гаҗәеп тугрылыкны соңгы сулышларынача саклаганнар. Аларны сагынып яшәгәннәр. Шул хисләрне балаларына да күчергәннәр. Сугыш чоры әниләре һәм сугыш чоры балалары – алар бүтән.

Тәпигә басарга тырышып,
Алар монда камылга ябышкан.
Буыннар ныклыгы,
Тазалык-
Учларына уылган арыштан.

**Җиңү- Левитан сөйләве, арттан чәчәкләр, шарлар сәхнәгә аталар.**
**1.** Утлы еллар үтте,
Җиңү килде.
Күпләр әйләнеп безгә кайтмады.
Исән-саулар Берлингача җитеп,
Туган авылларына атлады.
Җиңү көне, күктән күзем алмыйм,

Күгәрченнәр уйный очынып,
Зәңгәр күктә ап-ак канатлары
Көмеш кебек китә чагылып.

**2.** Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк җылый һәрбер солдат өчен,
Егермеләп миллион җан өчен.
Яңгыра җыр, тыйнак илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып халкымның.

1. Югалтулар алып килде сугыш,
Күпме дуслар кайтмый калдылар.
Шул дусларның йокыларын саклап,
Ак каеннар моңсу шаулыйлар.
Сагынабыз да, горурланабыз да ,
Онытылмыйлар корбан булганнар.
Бар бит менә безнең арабызда,
Җиңеп кайткан, исән калганнар.

1. Бөек Җиңүгә 78 ел! Илебез азатлыгы өчен көрәшкән солдатларны онытмыйк.
Исәннәрнең кадерен белик
Үлгәннәрнең каберен белик!
2. Бөек Җиңүгә 78 ел дип
Шатлык белән тибә йөрәкләр.
Тормышыгыз матур, көнелегез тыныч
Гомерегез озын булсын,
Безнең, сезгә шундый теләкләр.

**Ахмадуллин Альбина «Тынычлык җыры”.**